Сарански пенсионеры жинел автомобиль сатудан кергән һәм ярты миллион сумнан артык шәхси акчаларын мошенникларга кvчергән.
Россия Эчке эшләр министр-лыгынын Саранск шәһәре буенча 4 нче номерлы ОПП дежур частенә 74 яшьлек жирле кеше морәжәгать иткән. Ул ана карата кылынган мошенниклык турында хәбәр иткән. Гариза бирvче сvзләренчә, 7 январьда мессенджер буенча ана vзен элемтә бvлеге хезмәткәре дип таныштырган билгесез кеше шалтыраткан һәм ашыгыч рәвештә аларга почтага килергә, посылканы алырга кирәклеге турында хәбәр иткән. Аннары әнгәмәдәш анлатканча, әгәр андый момкинлек булмаса, аны саклау вакытын озайтырга момкин дигән. Зыян кvрvче кызга ышанган һәм анын таләбе буенча килгән смстан кодны хәбәр иткән. Шуннан сон әнгәмә тукталган.
Берничә сәгатьтән сон ана тагы Роскомнадзор вәкиле шалтыраткан. Ул дәvләт хезмәтләрендә анын шәхси кабинеты ватылган, дигән. Проблеманы хәл итv очен ул кабат смс-хәбәрдән билгесез кодны хәбәр иткән, шулай ук анын исеменнән мошенникларга анын шәхси мәгълvматларына керv момкинлеген чикләячәк оешма хезмәткәренә ышанычнамә (доверенность) рәс-миләштерергә ризалашкан.
Икенче конне пенсионерга янадан шалтыратып кичә ул мошенниклар белән аралашкан диләр: хәзер анын барлык акчалары, шулай ук анын милке куркыныч астында булуын анлаталар. Нәтижәдә, куратор тәкъдиме буенча, ул башта vз счетыннан 510 мен сум акча алган, аларны куркынычсыз счетларга кvчергән. Аннары жинел автомобилен 180 мен сумга ана шул ук әнгәмәдәш кинәш иткән кешегә саткан һәм ойдә сак-лана торган шәхси акчалары белән бергә кvрсәтелгән реквизитлар буенча кvчергән.
Зыян кvргән ир-ат мошенниклар белән аралашуын ана ярты миллион сумлык кредит алырга һәм гараж сатарга кушкач кына анлаган. Ул ботен акчасын куркынычсыз ячейкаларга кvчерергә тиеш булган. Уйланып, гариза бирvче полициягә морәжәгать иткән. Хәзерге вакытта әлеге факт буенча жинаять эше кузгатылган. Жинаять кылуда катнашы булган затларны эзләvгә юнәлдерелгән чаралар комплексы vткәрелә.
России Россия Эчке эшләр министрлыгынын Саранск буенча идарәсе хезмәткәрләре гражданнарга уяулык кvрсәтергә кирәклеге турында искә тошерә. Әгәр сезгә билгесез кеше шалтыратса, ул vзен хокук саклау органнары, дәvләт учреждениеләре, Үзәк банк хезмәткәре дип таныштырган һәм акчаларны куркынычсызландырырга, табыш яки остәмә керем алырга, нинди дә булса кушымта урнаштырырга яки сезнен банк счеты буенча санкцияләнмәгән операция турында хәбәр иткән икән, кичекмәстән сойләшvне туктатыгыз!